**ГЛАВА
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.06.2026 Балык Бистәсе штп № 145пг

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 06.09.2023 ел, №196пг карарына үзгәрешләр кертү турында

“Гражданнар оборонасы турында” 12.02.1998 № 28-ФЗ Федераль закон, РФ Хөкүмәтенең “Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында” 19.01.2026 №7 карары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 06.09.2023 ел, №196пг карарына (22.10.2024 №228пг редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 пунктында «хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 6 пунктта "һәм сугыш вакытында табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү" сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 15.2 пунктның 1 абзацында «хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 15.2 пунктның 2 абзацын кушымтада бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә:

«халыкка хәбәр итү системаларын, шул исәптән муниципаль һәм локаль халыкка хәбәр итү системаларын төзү, реконструкцияләү һәм файдалануга даими әзерлек халәтендә тоту;»;

1.5. 15.3 пунктның 1 абзацын кушымтада бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә:

«15.3. Халыкны эвакуацияләү, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне яклау буенча:»;

1.6. 15.3 пунктның 2 абзацын кушымтада бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә:

«халыкны эвакуацияләүне планлаштыруны, әзерләүне һәм уздыруны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне яклауны оештыру;»;

1.7. 15.6 пунктның 1 абзацында «килеп чыккан» сүзен төшереп калдырырга, «хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында» сүзләрен « мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында барлыкка килә торган:» сүзләренә алмаштырырга.;

1.8. 15.6 пунктның 2 абзацын кушымтада бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә:

«гражданнар оборонасының кирәкле көчләрен һәм чараларын булдыру, җиһазландыру һәм әзерләү, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасының кирәкле көчләрен җиһазлау һәм әзерләү, шулай ук аларның гамәлләрен планлаштыру;»;

1.9. 15.7 пунктның 1 абзацында "хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында килеп чыга торган хәвеф-хәтәрләр нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга.;

1.10. 15.7 пунктның 4 абзацын төшереп калдырырга;

1.11. 15.7 пунктның 1 абзацын кушымтада бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә:

«сакланып калган торак фондын инвентаризацияләү һәм аның торышын бәяләү, зыян күргән халыкны урнаштыру өчен аннан файдалану мөмкинлеген билгеләү, тораксыз калган кешеләрне вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларына урнаштыру;»;

1.12.абзац 12 пункта 15.7 исключить;

1.13.15.8 пунктның 1 абзацында «хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында барлыкка килә торган куркынычлар нәтиҗәсендә килеп чыккан»сүзләренә алмаштырырга.;

1.14. 15.8 пунктның 3 абзацында «сугыш вакытында» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.15. 15.9 пунктның 1 абзацында «һәм башка йогышлануга» сүзләрен «яисә башка йогышлануга» сүзләренә алмаштырырга;

1.16. 15.9 пунктның 2 абзацын кушымтада бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә:

"радиоактив зарарлануга (пычрануга) дучар булган территорияләрдә радиациядән саклану режимнарын кертү.»;

1.17. 15.11 пунктның 1 абзацында "хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган

чорда, сугыш вакытында килеп чыга торган куркынычлар нәтиҗәсендә»сүзләренә алмаштырырга.;

1.18. 15.14 пунктның 1 абзацында "хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында барлыкка килә торган куркынычлар булганда»сүзләренә алмаштырырга.;

1.19. 15.14 пунктның 2 абзацында «тыныч вакытта һәм сугыш вакытында» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.20. 15.14 пунктның 6 абзацында «тыныч вакытта һәм сугыш вакытында» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башлыгы

Р.Р. Ислямов